# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 5 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) ( Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 6; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 4; 2004, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның алтынчы өлешендәге беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Эшләрендә Татарстан Республикасының ике дәүләт телен белү һәм практикада куллану кирәк булган гражданнарга вазыйфаи окладтан 15 процентка кадәр күләмдә өстәмәләр билгеләнә.";

2) 12 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Сайлау бюллетеньнәре, Татарстан Республикасында референдумда тавыш бирү өчен бюллетеньнәр рус телендә бастырыла. Тиешле сайлау комиссиясе, референдум комиссиясе карары буенча бюллетеньнәр Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, ә кирәк очракларда шулай ук Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыклары күпләп яши торган территорияләрдә шул халыклар телләрендә бастырыла. Әгәр сайлау участогы, референдум участогы

өчен бюллетеньнәр ике яисә аннан күбрәк телдә бастырылса, рус телендәге текст һәр бюллетеньдә урнаштырылырга тиеш.";

3) 14 статьяның икенче өлешендә "эш башкару" сүзләреннән соң "Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә һәм шул ук вакытта" сүзләрен өстәргә;

4) 20 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Белдерүләрнең, афишаларның, башка күргәзмә мәгълүматның текстлары Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә язылa. Җитештереп чыгарыла торган продукциягә ярлыклар, инструкцияләр, этикеткалар рус телендә, шулай ук җитештерүченең ихтыяры буенча татар телендә һәм (яисә) Россия Федерациясе халыкларының туган телләрендә язылa.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2009 елның 3 декабре
№ 54-ТРЗ